**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 30 сентябрендәге 4122 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы карары белән расланган Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу вакытын озайту, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, «“ЮРТРЕЙД” юридик компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән төзелгән 2023 елның 18 октябрендәге АС-61-23 номерлы шартнамәне исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы белән расланган Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 29 маендагы 1503 номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 4367 номерлы, 2021 елның 16 апрелендәге 899 номерлы, 2022 елның

10 октябрендәге 3448 номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 4367 номерлы, 2023 елның 29 маендагы 1503 номерлы һәм 2024 елның 31 гыйнварындагы 347 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслау юлы белән үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 30 сентябрендәге
4122 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2019 елның 19 сентябрендәге 3320 номерлы карары белән расланган
Ротор, Һади Такташ, Нурсолтан Назарбаев урамнары һәм
Универсиада проспекты белән чикләнгән территорияне
планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, башка капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә.

2. Кызыл линияләр, юлларны, урамнарны, элемтә линияләрен, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын билгели торган линияләр күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә.

3. V «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән төзелеш тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә:

3.1. бүлек исемендә «V» санын «IV» санына алмаштырырга;

3.2. 3 нче «Яңа торак төзелеше характеристикасы» пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Кадастр номеры 16:50:070106:17 булган җир кишәрлеге өчен яшелләндерү проценты 0% дип кабул ителде, яшелләндерү буеча дефицит янәшәдәге участокларны яшелләндерү хисабына каплана.

Кадастр номеры 16:50:070106:17 булган объект өчен төзелеш проценты 85% дип кабул ителде»;

3.3. 4 нче «Социаль-көнкүреш һәм мәдәни төзелеш характеристикасы» пунктында таблицаны түбәндәге эчтәлектәге юл белән тулыландырырга:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Т-3 | Көнкүреш хезмәте күрсәтү объекты | Гомуми мәйдан-ның кв.м | 145,6 | 1 | 0,013» |

3.4. 5 нче «Транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикалары» пунктында:

3.4.1. 5.3 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы машиналары, шулай ук җиңел транспорт өчен карап тикшерелә торган территориягә (үзмәшгульлек үзәге) керүне һәм чыгуны оештыру торак йортлар җирләре буенча гамәлгә ашырыла. Нурсолтан Назарбаев урамы, 47/11 йорт, Дальняя урамы, 1/115 һәм 3 йортлар адреслары буенча торак йортлар территориясендә сервитут урнаштырырга тәкъдим ителә»;

3.4.2. 5.4 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Үзмәшгульлек үзәген парковка урыннары белән тәэмин итү Шаляпин урамындагы муниципаль парковкалар (192 номерлы муниципаль парковка зонасы) хисабына гамәлгә ашырыла»;

3.5. 6 нчы «Инженерлык-техник тәэмин итү системасын үстерү характеристикасы» пунктында:

3.5.1. 6.1 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Административ бинада хуҗалык ихтыяҗлары һәм эчү өчен файдаланыла торган суның чыгымы тәүлегенә – 0,14 куб.м, сәгатенә 0,3 куб.м тәшкил итәчәк.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан бирелгән 2023 елның 20 ноябрендәге 35420/06/16-29 номерлы техник мөмкинлек нигезендә проект белән, Нурсолтан Назарбаев/Ботаника урамнарындагы Ø 900 мм суүткәргечкә тоташтырып, Ø 63 мм челтәр проектлаштыру каралган»;

3.5.2. 6.2 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Исәпләүләр буенча административ бинадан хуҗалык ихтыяҗлары һәм эчү өчен файдаланылган суны чыгару күләме тәүлегенә – 0,14 куб.м, сәгатенә 0,3 куб.м тәшкил итә.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан бирелгән 2023 елның 20 ноябрендәге 35420/06/16-29 номерлы техник мөмкинлек нигезендә проект белән, проектлана торган бина янындагы 56,64; 53,11 л тамгалы коега тоташтырып, Ø 110 мм үзагышлы канализация челтәрен проектлаштыру каралган.

Су чыгаруның әлеге челтәрендәге агынты сулар үз чиратында Нурсолтан Назарбаев/1 нче Бөгелмә урамнарындагы Ø 800 мм канализация коллекторына тоташа торган Ø 500 мм коллекторга ага, бу «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан бирелгән 2023 елның 20 ноябрендәге 35420/06/16-29 номерлы техник мөмкинлеккә туры килә»;

3.5.3. 6.4 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Эреләндерелгән исәпләүләр буенча административ бинага җылылык йөкләнеше 0,0273 МВт (0,0235 Гкал/сәг) тәшкил итә.

Проект белән тоташу урыныннан (якындагы җылылык камерасы) проектлана торган бинага кадәр Ø 57х2,0 мм җылылык челтәре салу каралган (78 м озынлыктагы җылылык үткәргеч).

Шулай ук сүтелә торган үзәк җылылык пунктыннан Нурсолтан Назарбаев урамындагы 47/113 номерлы торак йортка кадәр һәм сүтелә торган үзәк җылылык пунктыннан Нурсолтан Назарбаев урамындагы 45А номерлы йорт янындагы җылылык камерасына кадәр җылылык белән тәэмин итү челтәрләрен сүтү күздә тотыла»;

3.5.4. 6.5 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Исәпләүләр буенча административ бинаның электр куллану күләме 8,1 кВт тәшкил итә.

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте хаты нигезендә проектлана торган территория өчен туклану үзәге итеп ТЭЦ-1 (ТП-71) подстанциясе тәкъдим ителә.

Территорияне төзү буенча эшләнгән планлаштыру карарларын исәпкә алып, түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

- 0,4 кВ кабель линияләре салу – 6,2 м;

- кертү-бүлеп тарату җайланмасы урнаштыру – 0,4 кВ;


- 0,4 кВ кертү-бүлеп тарату җайланмасында өч фазалы ток кабул итү җайланмалары өчен саклану рәвешендә сүндерү җайланмасы урнаштыру, аларны тулы булмаган фазалы режимда эшләүдән саклау, җиргә тоташтыру (бер фазалы ток кабул итү җайланмаларын артык көчәнештән саклау);


- аерым ток кабул итү җайланмалары өчен өзлексез тукландыру агрегатлары урнаштыру».

___________________

Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, границ зон планируемого размещения объектов социально - культурного и коммунально бытового назначения, иных объектов капитального строительства

Приложение №1 к изменениям, вносимым в проект планировки территории, ограниченной улицами Роторная, Хади Такташа, Нурсултана Назарбаева и проспектом Универсиады, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 19.09.2019 №3320




**ОБЪЕКТЫ ОБСЛУЖИВАНИЯ**

| Обозначение по генплану | Наименование | Единица измерения | Вместимость по проекту | Количество объектов | Площадь земельного участка (га) |
|---|---|---|---|---|---|
| **Предприятия торговли, общественного питания и бытового обслуживания** | | | | | |
| Т-3 | Объект бытового обслуживания | Кв.м общей площади | 145,6 | 1 | 0,013 |

**УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ**


| | |
|---|---|
| | Граница фрагмента внесения изменений в проект планировки территории |
| | Граница участка объектов нового строительства |
| | Красные линии существующие |
| 19 | Номера кварталов |
| | Сервитут |
| | Линия регулирования застройки |
| | **Общественно - деловые и коммерческие зоны, в том числе:** |
| | Зоны специализированной общественной застройки, в том числе: |
| | - зона торгово-бытового назначения |
| | **Жилые зоны** |
| | - зона многоэтажной жилой застройки |
| | - зона среднеэтажной жилой застройки |
| | **Зоны транспорта и улично-дорожной сети, в том числе:** |
| | - территория улиц и дорог |
| | **Зоны специального назначения, в том числе:** |
| | - зона объектов инженерной инфраструктуры |

Сокращения надписей, принятые на чертеже

1. Кр. л. ул. - Красная линия улицы
2. Тех.кор.инж.сущ.сетей - технический коридор инженерных сетей (существующих)

Фрагмент чертежа планировки территории с указанием красных линий, линий, обозначающих дороги, улицы, проезды, линий связи, объекты инженерной и транспортной инфраструктур

Приложение №2 к изменениям, вносимым в проект планировки территории, ограниченной улицами Роторная, Хади Такташа, Нурсултана Назарбаева и проспектом Универсиады, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 19.09.2019 №3320




## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

| | |
|---|---|
| | Граница фрагмента внесения изменений в проект планировки территории |
| | Граница участка объектов нового строительства |
| | Красные линии существующие |
| | Технический коридор инженерных сетей (существующих); |
| 19 | Номера кварталов |
| | Сервитут |
| | **Общественно - деловые и коммерческие зоны, в том числе:** |
| | Зоны специализированной общественной застройки, в том числе: |
| | - зона торгово-бытового назначения |
| | **Жилые зоны** |
| | - зона многоэтажной жилой застройки |
| | - зона среднеэтажной жилой застройки |
| | **Зоны транспорта и улично-дорожной сети, в том числе:** |
| | - территория улиц и дорог |
| | **Зоны специального назначения, в том числе:** |
| | - зона объектов инженерной инфраструктуры |
| | **Инженерные сети, в том числе:** |
| ТО | - проектируемые сети теплоснабжения |
| W1 | - проектируемые кабели электроснабжения 0,4 кВ |
| В1 | - проектируемые сети водоснабжения |
| К1 | - проектируемые сети водоотведения |
| × × | - демонтаж инженерных сетей |

## ОБЪЕКТЫ ОБСЛУЖИВАНИЯ

| Обозначение по генплану | Наименование | Единица измерения | Вместимость по проекту | Количество объектов | Площадь земельного участка (га) |
|---|---|---|---|---|---|
| **Предприятия торговли, общественного питания и бытового обслуживания** | | | | | |
| Т-3 | Объект бытового обслуживания | Кв.м общей площади | 145,6 | 1 | 0,013 |